ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28 июнь 2018 ел. № 3682

Башкарма комитетның «2018 елга Яр Чаллы шәһәре торак фондының торак урынынан файдалану (наем өчен түләү), торак урыннарын карап тоту өчен түләү күләме турында» 2017 елның 25 декабрендәге 8084 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 маддәсенең 3, 4 бүлекләре, 158 маддәсенең 4 бүлеге, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күп фатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм күп фатирлы йортта гомуми мөлкәт белән идарә итү, аны карап тоту һәм ремонтлау буенча сыйфаты тиешле дәрәҗәдә булмаган һәм (яки) билгеләнгән вакыттан озакка сузылган хезмәт күрсәтелгән һәм эш башкарылган очракта, торак урыннарын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 13 августындагы 491 нче Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә, халык хокукларын һәм ихтыяҗларын яклау системасының нәтиҗәлелеген күтәрү чаралары турында» 2010 елның 19 февралендәге 85 нче карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкка күрсәтелә торган торак һәм коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын күтәрү чаралары һәм алар өчен түләү күләменең нигезле булуы турында» 2010 елның 9 апрелендәге 250 нче карары, Башкарма комитетның 2017 елның 26 декабрендәге 8125 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең социаль наем килешүләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак биналарын наемга алу килешүләре буенча торак биналарны наемга алучылар өчен торак урыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү) күләмен исәпләү турында нигезнамә нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2018 елга Яр Чаллы шәһәре торак фондының торак урынынан файдалану (наем өчен түләү), торак урыннарын карап тоту

өчен түләү күләме турында» 2017 елның 25 декабрендәге 8084 нче карарына, кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

| Т/с | Түләү исеме | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге | 01.01.2018 елдан хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф (сумнарда) | 01.07.2018 елдан хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф (сумнарда) |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Торак урынын наемга алу өчен түләүнең база күләме | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 5,58 | 5,88 |
| 2. | Торак фонд белән идарә итү | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 2,85 | 2,85 |
| 3. | Гомуми файдалану урыннарын санитар карап тоту, шул исәптән: | аена гомуми торак мәйданының кв.м | | |
| 3.1. | - йорт эчендәге гомуми файдалану урыннарын җыештыру | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 1,85 | 1,85 |
| 3.2. | - йорт яны территориясен җыештыру | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 2,45 | 2,45 |
| 3.3. | - чүп үткәргечләргә хезмәт күрсәтү | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 1,45 | 1,45 |
| 3.4. | - дератизация (дезинсекция) | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 0,16 | 0,16 |
| 3.5. | - каты көнкүреш калдыкларын җыю, чыгару һәм утильләштерү (тариф каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча региональ оператор белән килешү төзегәнгә кадәр гамәлдә) | аена 1 кешегә | 47,50 | 55,50 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4. | Төзелеш корылмаларын һәм биналарның инженерлык системаларын ремонтлау һәм техник хезмәт күрсәтү, шул исәптән: | аена гомуми торак мәйданының кв.м | | |
| 4.1. | - торак биналар һәм йорт яны территориясен төзекләндерү | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 3,30 | 3,30 |
| 4.2. | - лифтлар | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 3,40 | 3,40 |
| 4.3. | - йорт эчендәге электр челтәрләре һәм электр җиһазлары | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 0,92 | 0,92 |
| 4.4. | - йорт эчендәге газ челтәрләре | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 0,25 | 0,27 |
| 4.5. | - торак йортлар эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системалары (бойлер булмаган) | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 2,23 | 2,23 |
| 4.6. | - торак йортлар эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системалары (бойлер булган) | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 2,77 | 2,77 |
| 4.7. | - йорт эчендәге үзәктән җылыту челтәрләре | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 2,78 | 2,78 |
| 4.8. | телевидениене коллектив кабул итү системалары (СКПТ) | хезмәт күрсәтелгән очракта, аена гомуми торак мәйданының кв.м | 0,55 | 0,55 |
| 4.9. | - янгынга каршы автоматика системасы (хезмәт күрсәтелгән очракта) | хезмәт күрсәтелгән очракта, аена гомуми торак мәйданының кв.м | 1,05 | 1,05 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4.10. | - домофоннар | хезмәт күрсәтелгән очракта, аена фатирдан | 25,00 | 25,00 |

2. Торак бинаны наемга алу өчен түләү күләме Башкарма комитетның 2017 елның 26 декабрендәге 8125 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең социаль наем килешүләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак биналарын наемга алу килешүләре буенча торак биналарны наемга алучылар өчен торак урыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү) күләмен исәпләү турында нигезнамәдә каралган коэффициентлардан файдаланып, торак бинаның сыйфатыннан һәм төзекләндерелүеннән, йортның урнашу урыныннан чыгып билгеләнә.

3. Әлеге карар 2018 елның 1 июленнән үз көченә керә.

4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.Ә. Абдуллин